**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 мартындагы 896 номерлы карары**

**«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 3 июнендәге «Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. «Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Планлаштыру проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре координаталары исемлегеннән, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлегенең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, төзелеш чорына планлаштырыла торган сервитут чикләре координаталары исемлегеннән,

файдалану чорына планлаштырыла торган сервитут чикләре координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 мартындагы
896 номерлы карары белән
расланды

**«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына түбәндәгеләр керә:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы.

II. Планлаштыру проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.


III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы

IV. Территорияне ызанлау проекты. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлегенең характерлы чикләре координаталары исемлеге, төзелеш чорына планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, файдалану чорына планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән текстлы өлеш.


Планлаштыру проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, линия объектын план буенча урнаштыру зоналарының характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план

буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, төзелеш чорына планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, файдалану чорына планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган документлар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

**I. Территорияне планлаштыру проекты.**
**График өлеш. Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы.**
**Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы**
**(1 бит)**



**(2 бит)**


С
З
В
Ю
УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ:
граница проекта планировки
граница зоны планируемого размещения проектируемого линейного объекта
граница зон планируемого размещения линейных объектов, подлежащих к реконструкции
характерная точка границ зон планируемого размещения линейного объекта
характерная точка границ зон планируемого размещения линейных объектов, подлежащих к реконструкции
проектируемая зона с особыми условиями использования территории линии наружного освещения (подземные кабельные)
ось объекта "Автомобильная дорога от ж.м.Кадышево до природного заказника "Голубые озера"
Схема расположения листов
1
2

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

Территорияне планлаштыру проекты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 3 июнендәге 2294 номерлы «Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары, «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесенең 2024 елның 2 ноябрендәге 400 номерлы муниципаль контракты нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә әзерләнде.

Административ яктан проектлана торган юл Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында урнашкан һәм проектлана торган парковка булган Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлының хәрәкәт өлеше булып тора.

Проектлау территориясе уртача континенталь климат зонасында урнашкан һәм төзелеш өчен климат буенча районлаштыру схемасы картасы нигезендә II ярдәмче районына керә, Россия Федерациясен районлаштыруның III юл-климат зонасына карый. Территория җир асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләре булу белән характерлана.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 елның 16 июнендәге 324 номерлы карары белән расланган төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы профиле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәнең 4.2 пункты нигезендә тыюлык территориясендә элек төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау рөхсәт ителә.

Территорияне планлаштыру проекты белән линия объектын план буенча урнаштыру чикләре билгеләнә. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең зурлыгы, 42.13330.2016 номерлы «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасын исәпкә алып, технологик яктан максатка ярашлы булудан, объектның функциональ билгеләнешеннән чыгып кабул ителә.

«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты «2.05.02-85 Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре* Автомобиль юллары» 34.13330.2021 кагыйдәләр җыелмасы нигезендә – «Җирле автомобиль юллары, килү юллары» классының IV категориясенә, Казан шәһәр округын шәһәр төзелеше ягыннан проектлауның

җирле нормативлары буенча төзелеш алып барылмаган территорияләрдәге җирле юлларга (IV категория) карый.

Территорияне планлаштыру проекты чигенең мәйданы – 30 200 кв.м.

Линия объектын урнаштыру зонасы чигенең мәйданы – 16 312 кв.м.

Линия объекты трассасының озынлыгы 1123 метрны тәшкил итә.

Проектлана торган участокның характеристикалары һәм параметрлары таблицада күрсәтелгән.

**Проектлана торган участокның техник характеристикалары һәм параметрлары**

| № т/б | Атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзелеш төре | - | Капиталь ремонт |
| 2 | Юл категориясе | 34.13330.2021 кагыйдәләр җыелмасы | IV |
| 3 | Төзелеш озынлыгы | М | 1123 |
| 4 | Исәпләнгән тизлек | км/сәг | 50 |
| 5 | Юл катламнары тибы һәм өслекнең төре | - | Капиталь, асфальт-бетон |
| 6 | Хәрәкәт полосалары саны | Данә | 2 |
| 7 | Машина юлының киңлеге | М | 6,00 |
| 8 | Хәрәкәт полосасы киңлеге | М | 3,00 |
| 9 | Тротуар киңлеге | М | 1,50 |
| 10 | Парковка | Машина урыны | 55 |

Юлның техник характеристикалары һәм параметрлары 34.13330.2021 «2.05.02-85 төзелеш кагыйдәләре һәм нормалары* Автомобиль юллары» кагыйдәләр җыелмасы һәм «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» 42.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы нигезендә кабул ителде.

Линия объектын план буенча урнаштыру зоналарының чикләре гамәлдәге җир кишәрлекләрен исәпкә алып билгеләнде.

Линия объектларын урнаштыру зоналары гамәлдәге нормативлар нигезендә билгеләнде. Әлеге объектларны башка ысул белән урнаштыру мөмкин түгел.

Махсус бүленгән җирләр зурлыклары проектлауның гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен, төзелешне оештыру буенча карарларны исәпкә

алып, җирләрне минималь мәҗбүри алу, технологик максатчанлык шартларыннан чыгып кабул ителә.

Объектларны төзү, алардан файдалану һәм төзекләндерү өчен махсус бүленгән җир полосасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 сентябрендәге 717 номерлы «Автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җирләрне бүлеп бирү нормалары турында»гы карары нигезендә кабул ителде.

Эшләр башкару һәм вакытлыча төзелеш хуҗалыгын урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирүне төзелеш-монтаж эшләре башланганчы рәсмиләштерү зарур.

## Инженерлык инфраструктурасы объектларына характеристика

Проект белән җирлек рельефына тышкы яктырту челтәрләрен, кар һәм яңгыр суларын чыгару каралган.

## Линия объекты урнашуга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Планлаштыру проекты чикләрендәге территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның дәүләт исәбенә кертелгән мәдәни мирас объектлары юк.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» объектында табигатьне саклау чаралары составына 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы федераль законның, Россия Федерациясе Җир кодексының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 елның 16 июнендәге 324 номерлы «“Зәңгәр күлләр” комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать тыюлыгы турында нигезләмәне раслау турында»гы карарының,

ГОСТ 17.4.3.02-85, ГОСТ Р 59070-2020, ГОСТ Р 59060-2020, ГОСТ 17.5.1.03-86, ГОСТ 17.5.1.06-84, ГОСТ Р 59057-2020, ГОСТ 17.5.3.05-84, ГОСТ 17.5.3.06-85 һәм башкаларның гамәлдәге норматив таләпләре нигезендә оператив һәм кисәтү чаралары, шул исәптән алга таба алып барылачак проект һәм төзелеш-монтаж эшләре кысаларындагы чаралар кирә.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Автомобиль юлы җитештерү циклы объекты булып тормый һәм үз составында куркыныч җитештерүләр һәм аларның участоклары юк. Шулай ук объектта куркыныч матдәләр юк. Димәк, авария нәтиҗәсендә куркыныч матдәләр чыгуны (чыгаруны) бетерү турында карарлар проектлаштыруга бирем белән билгеләнми һәм проектта күздә тотылмый.

Төзелеш корылмалары җимерелүгә бәйле аварияләр үсешен кисәтү эксплуатацияләүче оешма көчләре белән даими күзәтү һәм мониторинглау хисабына һәм, авария хәле барлыкка килгән очракта, ЮХИДИ органнары белән берлектә эксплуатацияләүче оешма карары буенча автомобиль юлы буенча хәрәкәтне туктатып (чикләп), мондый аварияләрнең башлангыч билгеләрен ачыклау белән ирешелә.

Проектлана торган объектлар урнашу районында куркыныч табигый процесслар (ишелүләр, сил ташкыннары, кар ташкыннары һ.б.) булмый.


Проектлана торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, шул исәптән проектлауның алдагы этапларында да, 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы «Биналар һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законында билгеләнгән чараларны күздә тоту зарур.

Проектлана торган линия объекты территориясенә иң якын янгын сагы бүлекчәсе – Казан шәһәре, Челюскин урамы, 51 йорт адресы буенча урнашкан 5 номерлы янгын часте.


Линия объектының карап тикшерелә торган территориясе мөмкин булган җимерелүләр, химик һәм радиоактив зарарлану, һәлакәтле су басу зоналарына эләкми. Гражданнар оборонасы буенча махсус чаралар әзерләү һәм үткәрү таләп ителми.

## III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.
## Территорияне ызанлау сызымы

**(1 бит)**



**(2 бит)**



С
З
В
Ю
16:00:000000:1427
16:16:212204:803
16:00:000000:1427:ЗУ1(1)
16:00:000000:1427:ЗУ1(2)
16:50:320201:172
16:50:320201:77
16:50:320201:75
16:50:320201:10
16:50:320201:179
16:16:212204:130
16:16:212204:109
16:16:212204:171
16:50:320201:133
16:50:320201:132
16:50:320201:102
16:50:320201:37
16:50:320201:39
16:50:320201:178
УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ:
граница проекта межевания
граница зоны планируемого сервитута на период строительства
граница зоны планируемого сервитута на период эксплуатации
существующий земельный участок с кадастровым номером
образуемый земельный участок с кадастровым номером
характерная точка зоны планируемого сервитута на период строительства
характерная точка зоны планируемого сервитута на период эксплуатации
ось объекта "Автомобильная дорога от ж.м.Кадышево до природного заказника "Голубые озера"
Схема расположения листов
1
2

## IV. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше

«Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты Казан шәһәре Авиатөзелеш районы территориясендә территорияне планлаштыру проекты составында эшләнде.

Территорияне ызанлау проекты территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен формалаштыру максатыннан әзерләнде.

Территорияне ызанлау проекты линия объектын төзү, реконструкцияләү, аннан файдалану өчен проектлана торган урман участогы чикләрен билгеләү, шулай ук ачык сервитутның тәкъдим ителә торган чикләрен билгеләү өчен эшләнде.

Җирләрдән рациональ файдалану максатыннан проектта объектны төзегәндә, реконструкцияләгәндә, аннан файдаланганда җирләрдән минималь файдалану күздә тотыла.

Карап тикшерелә торган территория 16:00:000000:1427, 16:16:212204:803 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан.

23 661 кв.м мәйданлы урман участогы 16:00:000000:1427 кадастр номерлы җир кишәрлеге чикләрендә формалаштырылган, билгеләнгән тәртиптә урман фонды җирләрендә, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районының шәһәр яны урманчылыгы, Биектау участок урманчылыгы административ чикләрендә урман кварталы составында бирелгән, урман-таксация бүлемтегенең бер өлеше: 37 квартал (76, 86, 87, 88, 90, 93, 94, 95, 96 бүлемтекләре өлешләре). Җир кишәрлеге Казан шәһәре муниципаль милкендәге 16:00:000000:1427 кадастр номерлы җир кишәрлеген (алга таба – беренчел җир кишәрлеге), үзгәртелгән чикләрдә беренчел җир кишәрлеген саклаган хәлдә бүлеп ясала. Ясала торган җир кишәрлеге күп контурлы.

2020 елның 31 июлендәге 254-ФЗ номерлы «Инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтү буенча өстенлекле проектларны гамәлгә ашыру максатыннан аерым мөнәсәбәтләрне җайга салу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә инфраструктура объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре мондый инфраструктура объектлары территориясен планлаштыру буенча расланган документлар белән билгеләнә. Урман фонды җирләре чикләрендә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре

шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексы, шәһәр яны урманчылыгының урман хуҗалыгы регламенты нигезендә билгеләнгән.

Ясала торган җир кишәрлеге өчен Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясы нигезендә линия объектларын төзү, реконструкцияләү, алардан файдалану рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү зарур.

Линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә җир кишәрлекләрен ясау максатыннан кадастр эшләре башкару таләп ителә. Ясала торган күп контурлы җир кишәрлеге турындагы белешмәләр, шул исәптән беренчел һәм ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы, рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләр, мөмкин булган ясау ысуллары 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 таблица

**Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге**

| **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Беренчел җир кишәрлегенең милек формасы** | **Беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше** | **Мәйданы, кв.м** | **Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Ясалу ысулы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 16:00:000000:1427 | Муниципаль | Табигый ландшафт | 16:00:000000:1427 ЗУ1<br><br>16:00:000000:1427:ЗУ1 (1);<br>16:00:000000:1427:ЗУ1 (2) | 23661<br><br>12459;<br>11202 | Линия объектларын төзү, реконструкцияләү, алардан файдалану | Беренчел җир кишәрлеген саклаган хәлдә үзгәртелгән чикләрдә бүлү |

Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен ясала торган җир кишәрлеген мәҗбүри алу зарурлыгы юк, чөнки 16:00:000000:1427 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеге  Казан шәһәре муниципаль милкенә керә.

16:00:000000:1427, 16:16:212204:803 кадастр номерлы җир кишәрлекләре өлешенә карата «Кадыш торак массивыннан “Зәңгәр күлләр” табигать тыюлыгына кадәр автомобиль юлы» линия объектын төзү һәм реконструкцияләү һәм әлеге линия объектының махсус бүленгән полосасы чикләрендә инженерлык коммуникацияләре салу кысаларында сервитутлар билгеләү тәкъдим ителә. Билгеләү планлаштырыла торган сервитут турында мәгълүматлар 2 нче таблицада китерелгән.

2 таблица

**Төзелеш чорына планлаштырыла торган сервитутлар исемлеге һәм аларның мәйданы турында мәгълүматлар**

| **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ачык сервитут мәйданы** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре** |
|---|---|---|
| 16:00:000000:1427 | 23661 | Табигый ландшафт |
| 16:16:212204:803 | 6540 | Агач әзерләү; сагыз әзерләү; агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю; азык-төлеккә караган урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю; аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру; авыл хуҗалыгын алып бару; фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру; рекреация эшчәнлеген башкару; урман плантацияләре булдыру һәм алардан файдалану; урманда җимеш, җиләк, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре үстерү; урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү; җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны тикшерү һәм чыгару; сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны, диңгез портларын, диңгез терминалларын, елга портларын, причаллар төзү һәм алардан файдалану; линия объектларын төзү, реконструкцияләү, алардан файдалану; дини эшчәнлек алып бару; Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр |

16:16:212204:803 кадастр номерлы җир кишәрлеге чикләре өлешенә карата әлеге җир кишәрлеге аша җәяү яисә транспортта үтүне тәэмин итү өчен ачык сервитут урнаштыру тәкъдим ителә. Билгеләү планлаштырыла торган сервитут турында мәгълүматлар 3 нче таблицада китерелгән.

3 таблица

**Файдалану чорына планлаштырыла торган сервитутлар исемлеге һәм аларның мәйданы турында мәгълүматлар**

| **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ачык сервитут мәйданы** | **Рөхсәт ителгән файдалану төрләре** |
|---|---|---|
| 16:16:212204:803 | 6540 | Агач әзерләү; сагыз әзерләү; агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю; азык-төлеккә караган урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю; аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру; авыл хуҗалыгын алып бару; фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру; рекреация эшчәнлеген башкару; урман плантацияләре булдыру һәм алардан файдалану; урманда җимеш, җиләк, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре үстерү; урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү; җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны тикшерү һәм чыгару; сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехник корылмаларны, диңгез портларын, диңгез терминалларын, елга портларын, причаллар төзү һәм алардан файдалану; линия объектларын төзү, реконструкцияләү, алардан файдалану; дини эшчәнлек алып бару; Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясы 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр |